КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 февраль г.Казань № 127

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибе турында» 2011 ел, 12 август, 660 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибе турында» 2011 ел, 12 август, 660 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 19 июнь, 391 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка «, Россия Федерациясе Җир кодексының $V^7$ бүлегендә каралган очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

3 пунктның 2 һәм 9 пунктчалары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин